**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№182**
**17.01.2025**

«Яр Чаллы лидеры - 2025» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрү, коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә 2025 елның февраль-мартында Яр Чаллы шәһәрендә «Яр Чаллы лидеры - 2025» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) конкурсның эксперт советы составын, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 60 000,00 (алтмыш мең) сум 00 тиен күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 17 гыйнварындагы
182 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә «Яр Чаллы лидеры - 2025»
балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре
лидерларының шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәрендә «Яр Чаллы лидеры - 2025» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру максатларында үткәрелә.

2. Әлеге нигезләмә 2025 елгы конкурс чараларын үткәрү тәртибен һәм срокларын, эчтәлеген һәм катнашучыларның категорияләрен билгели.

## 2. Максатлар һәм бурычлар

3. Конкурсның максаты: коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын ачыклау, шулай ук бүләкләү һәм аларга булышлык итү, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрүдә ярдәм күрсәтү.

4. Конкурсның бурычлары:

1) иҗтимагый хәрәкәт, яшьләр сәясәте, яшь гражданнарны тәрбияләүдә инновацион технологияләрне үстерү өчен шартлар тудыру;

2) балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең эшчәнлеген стимуллаштыру;

3) дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләрен популярлаштыру;

4) коммерцияле булмаган оешмаларның, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләрнең лидерларын һәм җитәкчеләрен дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашуга җәлеп итү.

## 3. Конкурсны оештыручылар

5. Конкурсны оештыручылар булып Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» шәһәр балалар һәм яшьләрнең иҗтимагый берләшмәләре үзәге МАУ һәм Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе тора. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

6. Конкурсның партнерлары:

1) Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;

2) Яр Чаллы шәһәренең «Беренчеләр хәрәкәте» балалар һәм яшьләрнең иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең җирле бүлеге (алга таба – «Беренчеләр хәрәкәте»).

## 4. Эксперт советы

7. Конкурсны үткәрү һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган, конкурсның эксперт советы төзелә.

8. Конкурсның эксперт советы:

1) конкурсның эчтәлеге, үткәрү тәртибе, конкурс программасы, катнашучылар составы, шул исәптән һәр номинациядә катнашучылар составы буенча оештыру комитетына тәкъдимнәр кертә;

2) катнашучыларны бәяләүне гамәлгә ашыра;

3) номинацияләрдә җиңүчеләр һәм призерлар, шул исәптән махсус номинациядә җиңүчеләр исемлеген формалаштыра;

4) читтән торып һәм урындагы этапларны үткәрү йомгаклары буенча һәр номинациядә махсус номинация билгели.

## 5. Конкурста катнашучылар һәм номинацияләр

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) Балалар иҗтимагый берләшмәсе лидеры (11-13 яшь);

Әлеге номинациядә катнашуга түбәндәге катнашучылар категориясе кертелә:

- балалар иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар;
- өстәмә белем бирү учреждениеләренең шәһәр программалары активларында катнашучылар;
- Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» башлангыч бүлекчәләренең тематик клубларында катнашучылар;

2) Балалар һәм (яки) яшьләр иҗтимагый берләшмәсе лидеры (14-16 яшь).

Әлеге номинациядә катнашуга түбәндәге катнашучылар категориясе кертелә:

- балалар һәм (яки) яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар;
- өстәмә белем бирү учреждениеләренең шәһәр программалары активларында катнашучылар;
- Яр Чаллы шәһәренең «Беренчеләр хәрәкәте» тематик клубларында катнашучылар;

3) Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» башлангыч бүлекчәсенең Беренчеләр Советы лидеры (14-16 яшь).

Әлеге номинациядә катнашуга түбәндәге катнашучылар категориясе кертелә:

- Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» башлангыч бүлекчәсенең Беренчеләр Советында катнашучылар;
- Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» башлангыч бүлекчәләренең тематик клубларында катнашучылар;

4) Яшьләр иҗтимагый берләшмәсе лидеры (17-25 яшь).

Әлеге номинациядә катнашуга түбәндәге катнашучылар категориясе кертелә:

- яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар;
- студентлар берләшмәләрендә, шул исәптән студентлар советларында, клубларында, иреклеләр отрядларында, Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү

оешмалары, югары белем бирү оешмалары базасында «Беренчеләр хәрәкәте» башлангыч бүлекчәләренең Беренчеләр Советында катнашучылар.

## 6. Конкурсны үткәрү тәртибе

10. Конкурс 2 этапта үткәрелә:

11. I этап – читтән торып, сайлап алу;

12. Конкурсны читтән торып үткәрү этабында катнашу өчен катнашучылар https://forms.gle/GXsVHh6saBEBmh9B8 сылтамасы буенча заявка бирәләр һәм gcoonch@mail.ru электрон почта адресына түбәндәге конкурс материалларын җибәрәләр:

1) расланган форма буенча конкурсантның анкета-портфолиосы;

2) «Безнең заман герое» эссесы. Форматы: текстлы редакторда әзерләнгән документ, күләме 1 биттән артык түгел;

3) «Команда лидеры буларак минем миссиям» видеороликы. Форматы: конкурсантның Вконтакте социаль челтәрендәге шәхси битендә видеороликка сылтама;

4) «Безнең заман герое» фотокүргәзмәсе өчен, героик гамәл кылган мөһим кеше турында фотографияне һәм кыскача мәгълүматны үз эченә алган материаллар.

13. Конкурс материалларын тапшыру срогы – 2025 елның 27 гыйнварына кадәр.

14. Конкурсның эксперт советы тарафыннан читтән торып үткәрү этабы йомгаклары буенча һәр номинациядә 8 әр финалист билгеләнә.

15. Читтән торып үткәрү этабы финалистлары исемлеге, тәкъдим ителгән барлык материаллар конкурсның эксперт советы тарафыннан бәяләнгәннән соң билгеләнә һәм 2025 елның 3 февраленнән дә соңга калмый, эксперт советы җыелышында раслана.

16. 2 этап – урында, финал.

17. Конкурсның урындагы этабы түбәндәге конкурс сынауларын үткәрүне күздә тота:

1) конкурсантның «Мин һәм минем командам» иҗади презентациясе. Иҗади презентациядә конкурсант һәм конкурсант тәкъдим иткән иҗтимагый берләшмә әгъзалары арасыннан 2 кешедән 4 кешегә кадәр хуплау төркеме катнашучылары катнаша.

Чыгышның регламенты - 5 минутка кадәр, жюри сорауларына җаваплар – 10 минутка кадәр.

Үткәрү датасы - 2025 елның 13 феврале.

2) конкурсантның 2024 елда турыдан-туры катнашкан социаль проектны презентацияләү-яклавы. Социаль проектны презентацияләү-яклау конкурсант тарафыннан индивидуаль үткәрелә.

Чыгышның регламенты - 5 минутка кадәр, жюри сорауларына җаваплар - 10 минутка кадәр.

Үткәрү датасы - 2025 елның 14 феврале.

3) «Яр Чаллы лидерлары форумы - 2025» конкурсантның коммуникатив күнекмәләрен һәм командада эшли белүен күрсәтә торган конкурс чаралары комплексын үз эченә ала.

«Яр Чаллы лидерлары форумы - 2025» программасы турында конкурсантларга аны үткәрүгә кадәр 5 көннән дә соңга калмый хәбәр ителә.

Үткәрү датасы — 2025 елның 15 феврале.

18. Конкурсны үткәрү барлык этапларда да бәяләүне күздә тота (0 дән 15 баллга кадәр):

1) конкурста катнашучы турыдан-туры катнаша торган иҗтимагый берләшмә эшчәнлегенең технологияләре һәм методикасы, инновацион алымнары һәм ысуллары;

2) катнашучының оештыру, иҗади һәм коммуникатив сәләтләре;

3) катнашучының идарә итү сәләтләре, осталыгы һәм күнекмәләре;

4) конкурсантның белем дәрәҗәсе: хокук белемнәре, иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә якын килү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенең төп юнәлешләре, принциплары, механизмнары;

5) мәгълүмат культурасы.

## 7. Конкурска йомгак ясау

18. Конкурста катнашучыларның барысы да электрон рәвештә конкурста катнашучы сертификатлары белән бүләкләнә, финалга чыгучылар дипломнар белән бүләкләнә.

19. Һәр конкурс номинациясендә 1 (бер) конкурс җиңүчесе, 2 (ике) конкурс призеры билгеләнә. Конкурста җиңүчеләр һәм призерлар конкурсны оештыручылар һәм партнерлардан дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.

20. Әлеге нигезләмәнең 9 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән конкурс номинациясендә җиңүче 2025 елның җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында «Беренчеләр вакыты» шәһәр профильле сменасына юллама белән бүләкләнә.

21. Әлеге нигезләмәнең 9 пунктының 2, 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән конкурс номинацияләрендә җиңүчеләр 2025 ел йомгаклары буенча Яр Чаллы шәһәре Хакименең яшьләр сәясәте өлкәсендәге исемле стипендиясе белән бүләкләүгә тәкъдим ителә.

22. Конкурсантларның «Социаль проектны презентацияләү-яклау» конкурсы сынавы кысаларында, әлеге нигезләмәнең 9 пунктының 2, 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән һәм 2025 елда кабат тормышка ашыру күздә тотылган социаль проектлары, җыелган баллар йомгаклары буенча «Беренчеләр инициативасы» шәһәр конкурсы кысаларында хуплауга тәкъдим ителә.

23. Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү тантанасы Яр Чаллы шәһәренең «Беренчеләр хәрәкәте» Беренчеләр Советларының II Слеты кысаларында үткәрелә.

Башкарма комитет Аппараты<br>Җитәкчесе урынбасары,<br>эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева